**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 18 февраль № 99

г. Казань

Менделеевск муниципаль районында җир кишәрлеген бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Связьтранснефть» – «Идел-Кама ҖТЭИ» акционерлык җәмгыятенең Менделеевск муниципаль районында урнашкан, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының муниципаль милкендә булган 0,125 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:27:070601:181 кадастр саннары белән кадастр паспортында күрсәтелгән чикләрдә, элемтә объектлары урнаштыру максатларында, сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\99.docx